***«ГАЖУР»** чыгара торган **«Кызыл Татарстан», «Крестьян гәзите», «Кызылармеец», «Яшь Ленинчы», «Кызыл иптәшләр», «Чаян»** һәм **«Авыл яшьләре»***

*Подписка Чернышевский урамында 21 нче йортта кабул ителә. Декабрь өчен подписка яздыруны хәзердән үк кайгырта башлагыз.* [12]

Гасыр башында бүгенге кебек камиллеккә ирешкән техник чаралар булмаса да реклама бирүчеләр кешене кызыксындыра алырлык ысуллар таба белгәннәр. Катлаулы техник мөмкинлекләр сораса да, реклама бирүче үз рекламасын ничек тә аңлаешлы, күзалларлык, мәгълүматны визуаль кабул итү өчен җиңелләштерергә тырышкан. Моның өчен шрифт, төс, калынлык кебек мөмкинлекләрдән файдаланыла. Ә 1929 елда гомумән дә рекламада рәсемнәр файдалану, аны үтемле итү гамәлдә актив кулланыла башлый.

**Әдәбият**


1. Низамов И.М. Татар рекламы һәм матбугат. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1997. Б.9
2. Низамов И.М. Күрсәтелгән хезмәт. Б.45
3. Низамов И.М. Күрсәтелгән хезмәт. Б.33
4. Яшь ленинчы. 1925. 18 февр.
5. Яшь ленинчы. 1925. 26 март.
6. Яшь леничы. 1929. 15 гыйнв.
7. Яшь ленинчы. 1925. 1 дек.
8. Яшь ленинчы. 1925. 10 ноябрь.
9. Яшь ленинчы. 1929. 23 июль.
10. Яшь ленинчы. 1929. 31 июль.
11. Яшь ленинчы. 1929. 28 июнь.
12. Яшь ленинчы. 1925. 10 ноябрь.


## ФЛОРИД АГЗАМОВ – МАСТЕР САТИРЫ


**И.Ф. Фаттахов,**
Казанский (Приволжский) федеральный университет (Россия)
доцент
E-mail: ilgam.fattakhov@mail.ru



**Аннотация:** Раскрывается талант Флорида Агзамова как сатирика. Анализируются его фельетоны и политические памфлеты.



**Ключевые слова:** Флорид Агзамов, сатира, памфлет, Горбачёв, Ельцин, Гайдар.



**Summary:** Article reveals Florid Agzamov's talent as a satirist and analyzes his satires and political pamphlets.



**Keywords:** Florid Agzamov, satire, pamphlet, Gorbachev, Yeltsin, Gaidar.

## ФЛОРИД ӘГЪЗАМОВ – САТИРА ОСТАСЫ

Сүземне лирик чигенештән башлыйм. 1992 елның эссе июль ае иде. Казан дәүләт университетының журналистика факультетына укырга керергә дип имтиханнар тапшырып йөргән чак. Иҗади имтиханда Мөнҗия Борһан кызы Мәрдиева инша яздырды. Аннары Россия тарихыннан сынау бирдек. Август башында икенче уку корпусының 13 нче этажында урнашкан деканатка «*собеседование*»гә килдек. Бер-бер артлы декан янына керә башладык. Миңа да чират җитте. Беренче карашка кырыс кыяфәтле күренгән Флорид Әгъзамов, Ислам Әхмәтҗанов белән бергәләп абитуриентларны кабул итә икән.

– Илһам, нигә безгә керергә уйладың? – дип сорады таләпчәнлеге тавышына чыккан Флорид абый.

– Сездә укытуның практика ягы көчле, ә татфакта теоретик белемне тирәнтен бирәләр дип ишеттем.

Сүзгә Ислам Галиәхмәт улы кушылып, рәхәтләнеп көлдереп алды:

– Ундүрт «тавык» арасында бер «әтәч» булып йөрерсең, Илһам!

– Уйлап бетер, энем! – диде йомшак тавышы белән Флорид Имамәхмәт улы.

Ләкин мин журфак кызларыннан «куркып», татфакка киттем. Кыска истәлегем шуның белән тәмам.

...Кулымда «Флорид Әгъзамов: осталар остазы» исемле зәңгәрсу, каты тышлы китап. Ул Татарстан Республикасында журналист кадрлар әзерләүгә нигез салучыларның берсе, чирек гасырдан артык Казан университетының журналистика бүлеген җитәкләгән күренекле галим, атаклы журналист Флорид Имамәхмәт улы Әгъзамовның тууына 75 ел тулу уңаеннан нәшер ителгән. Аның төзүчесе – Ф.И.Әгъзамовның тугрылыклы шәкерте, дәвамчысы, филология фәннәре докторы, профессор Васил Заһит улы Гарифуллин.

Бу китапның өченче бүлегенә Флорид Әгъзамов 1990 елларда иҗат иткән фельетоннар, памфлетлар кертелгән. Аларның баш исемнәре дә игътибарны җәлеп итә: «И дусларым, дусларым...» (исеме популяр татар җырыннан алынган), «Түгәрәкләнү (моңсу фельетон дип атый)», «Талашу», «Кызым, сиңа әйтәм...», «Депутат буласың килсә...», «Адашу», «Ташбакачылык», «Конкретика», «Мөгез чыгару», «Аллергия» һ.б.ш. Чыннан да, журналист үз каләмен сатира өлкәсендә дә уңышлы сынап карады. Ул туксанынчы еллардагы сүз ирегеннән киң кулланып, шул заманның монафыйкъ адәмнәрен – ялганчы түрәләрен, алдакчы депутатларын – кыю тәнкыйть утына тотты.

«И дусларым, дусларым...» памфлетын «Кесәңдә йөз сум булганчы, йөз дустың булсын» дигән татар халык мәкале белән башлап җибәрә. Ләкин Ельцин заманында бу мәкальнең дөреслеген шик астына ала. 100 сум акча, ягъни Ельцинның 10 меңе күпләрнең төшенә генә керә, ди. Кесәңдә акчаң булса, дуслар тиз табыла дип искәртергә дә онытмый автор. Ул шушы урында мәшһүр Тукаебызның атаклы фикерен искә төшерә:

*«Акча барда, бар да дуст шул, бар да яр.*

*Акча исе чыкмый торса, бар да яныңнан таяр!»* [1, б. 76.]

Шушындый кызыклы, гыйбрәтле башламнан соң Ф. Әгъзамов бик кискен борылыш ясый: сүзе бушлай дуслар турында икән. Кесәсендә сукыр бер тиене булмаган килеш, дусларым буа буарлык дип гаҗәпләндерә ул укучыны. «Кемнең генә дусты түгел мин хәзер!», – дип мактанып та ала әле. Памфлетчының «дуслары» менә кемнәр икән: телевизорда программаны алып баручы, җырчылар, эшкуарлар, сәясәтчеләр... Алар барысы да аңа дустым дип эндәшә. Әмма алып баручы мөстәкыйльлеген яклаган өчен сайлауда катнашмаган Татарстанны сүгә икән. Үзенә «дус» дип дәшкән өчен барлык җырчыны да яратып булмый, ди. Ялган аракы тәкъдим итүче эшкуарлар да «дус» булалмый, чөнки халыкның кесәсендә җилләр уйнаганын белмиләр. Сәясәтчеләр арасында «дусларым» аеруча күп, дип яза. Сайлау кампаниясендә алар матур катнашып, депутатлар булып китәләр. Андый әрсез, бушлай «дуслар» белән нишләргә белми автор. Ихтыярсыздан җыр сузып җибәрә:

*«Искерсәм дә, исерсәм дә,*
*Иске дусларга ярыйм!»* [1, б. 77.]

Әмма яңа дусларның үзе белән нишләрен белә ул. Ярлы-ябагайга төкерәчәк кенә алар, ди.

Шулай итеп, Ф.Әгъзамов антитеза алымын кулланып, иске дусларны яңа «дуслар»га каршы куя. Памфлет ахырында иске дусларны яңаларына алыштырырга ярамый дигән төп нәтиҗәгә килә.

Кабатлаудан төзелгән синтаксик фигураларның киң мөмкинлеген файдалану психологик дәлилләүнең көчен бермә-бер арттыра, мисал өчен, кулланылган анафора үзенә игътибарны юнәлтә һәм психологик дәлилләүнең укучыга тәэсир итүен көчәйтә:

*«Сәясәтчеләре... сәясәтчеләрне инде әйткән дә юк.»* [1, б. 76]

Памфлетта үткен сәяси сатирага да уңышлы мисал бар. Ф.Әгъзамов курыкмыйча язган:

*«Астына су керә башласа, Илбашы* (Россиянең беренче президенты Б.Н.Ельцин күздә тотылган. – И.Ф.) *якын дустыма әверелә. Әйтерсең лә, аның белән пошы аткан, мунча кергән, чәркә тоткан. Күптән түгел генә сайлау кампаниясендә катнашкан депутатлыкка кандидат, ә хәзер инде чын депутат дусларым бөтен илгән таралган. Берничә көн эчендә мине ыштансыз калдырган Гайдар да, 500 көн эчендә илне өр-яңа итәсе Явлинский да, Президент булып калса, мине Монголиягә куачак Жириновский да, 70 елдан артык дәвер әкият дөньясында яшәткән идеология вәкиле Зюганов та, тагын әллә кемнәр, әллә кемсәләр...» [1, б. 76]*

«Түгәрәкләнү» фельетонын моңсу дип атаган. Ни өчен? Авторның танышы гомере буе йокы бүлмәсе гарнитуры алырга хыялланып үлеп китә. Үлеменең объектив сәбәпләре билгеле: күршедәге кибеттән булган мебельне алырга акчасы җитми, хезмәт хакының бер өлешен саклык кассасына сала, тора-бара мебель дефицитка әйләнә, танышының блаты юк, ул хатыны эшли торган заводта мебель чиратына баса, инде чират җиткәч кенә Егор Гайдар

бәяләрне бәйдән ычкындыра, саклык кассасында җыелган акчасы яна, өмете бөтенләй сүнә, авырый башлый һәм җан тәслим кыла. Гомер буе берьярымлык караватта йоклап җәфаланган ир-ат кушкойка турында хыялланып та, гомеренең азагында хыялы «тормышка ашкан»: үлгәч, берьярымлык караватта берүзе иркенләп ята икән. Хатыны да караватлы калган, барысы да түгәрәкләнгән.

«Талашу» фельетонының исеме дә куркыныч. Пенсионер лаеклы ялга лаекмы? Лаек диярсез. Автор пенсиягә чыккач, тынычлап ял итәрмен дип уйлый. Ләкин ялгыша. Радиоалгычны ачса, борчулы хәбәрләр генә ишетә: сугыш, забастовка, пикет...

Транспортта бушлай йөрү өчен документ алырга собеска барганда трамвайда бер хатын-кызның аягына ялгыш баса. Гафу үтенсә дә, хатын аңа кычкыра башлый.

Пенсионерга беркайда да тынычлык юк икән. Трамвайдан төшкәч, юлны аркылы чыкканда, светофорның яшел утына өлгерми. Шоферлар сүгенеп уздылар, ди. Авторның йөрәге тагын бер чәнчеп ала, бу юлы валидолсыз котыла алмый.

Райсобеста да тавыш-талаш. Берсенең ире өчен көнләшеп, ике хатын талаша. Документның тышлыгы бетте, бер атнадан килерсең, дип кире боралар аны.

Пенсионер кәефсез килеш өенә кайта. Әбәд әзерләгәндә, радионы тыңлый: анда татарча талашалар, ә телевизорны кабызса, анда да спектакльдә талашып яталар икән.

«Талашу» фельетоны бик гыйбрәтле, кеше бу фани дөньяга мәңге яшәргә килдеме дигән риторик сорау куя автор.

«Кызым, сиңа әйтәм...» фельетонында автор акчаны каһәр дип атый, акчаны боз белән чагыштыра, ул бик тиз эреп бетә, ди. Мәктәп укытучыларына ике ай буе хезмәт хакы түләнми икән. Бу хәл өчен, әлбәттә, директор гаепле дип саный укытучы халкы. Фельетонның исеме дә игътибарга лаек, халык мәкален баш исем итеп сайлаган автор.

«Сатира өлкәсендә Ф.Әгъзамовны кабатлау алымының остасы буларак билгеләп үтәргә мөмкин», – дип яза В.З. Гарифуллин [2, б. 11].

«Депутат буласың килсә...» памфлетының темасы бүген дә актуаль яңгырый, чөнки быел көз ГосДумага булачак сайлауны исәпкә алсаң, бигрәк тә. Моның шулай икәнлеген белер өчен памфлетның баш өлешен укып карыйк әле, җәмәгать:

*«Рәсәйнең Федераль Советына вә Дәүләт Думасына сайлау кампаниясендә урак өсте җитеп килә. Депутатлыкка кандидатлар күрсәтү башланды да инде. Татарстанда да сәясәткә мөкиббән киткән адәмнәрнең төн йокылары качкан, имеш. Тавык төшенә тары керә дигәндәй, кайберәүләр черем итеп алган чакларында депутат мөнбәрендә төкерек чәчә-чәчә, нотык сөйлиләр, имеш. ...»* [1, б. 81]

Памфлетның тексты нигездә боерык җөмләләрдән төзелгән:

*«– Коммунистларның тетмәсен тет. ...*

*– Укның иң очлысын Хасбулатовларга турыла. ...*

*– Бүгенге демократлар өлешенә дә көмеш чыгар. ...*

*– «Бүленмәс вә бердәм Россия!» дигән лозунг күтәр. ...*

*– Бәяләрне даими күтәреп торуны яклап чык. ...*

*– Американы үтереп макта. ...*

*– Бар халыкка алтын таулар вәгъдә ит. ...*

*– Бер дәүләт кешесе белән фоторәсемгә төшәргә тырыш. ...*

*– Гәзит-радио вә телевидение тирәсеннән шайтан суына хирысрак берике журналист белән әшнәлек урнаштыр. ...*

*– ... иртәгә үк Президент фиркасына язылы. ...»* [1, б. 81-82]

Сирәк булса да, биредә шарт җөмләләр дә очрый:

*«Әгәр дә мәгәр депутат буласың килсә, болай ит: ...*

*(Төшәлмәсәң, фотомонтаж ясат).*

*(Рюмка чәкештереп төшә алсаң, бигрәк тә яхшы).*

*Шушы киңәшләрне җиренә җиткереп вә арттырып үтәсәң, депутат мандаты йөз проценты белән кесәмдә, дип сана.»* [1, б. 81-82]

Памфлетчы халкыбыз мәкальләрен дә кулланган:

*«Тавык төшенә тары керә дигәндәй... (тик әлеге мәкальнең «...ашамаса – тагы керә» дигән икенче өлешен автор төшереп калдырган. – И.Ф.) Киңәшле эш таркалмас, диләр ич. Хәйләсез – дөнья файдасыз.»* [1, б. 81-82].

«Адашу» – сәяси памфлет. Монда да сайлау темасы сурәтләнә. Телевизордан 90 елларда рекламаланган сәяси партияләргә автор характеристика бирә: ЛДПР (Жириновский үз кесәсеннән аракы шешәсенең борынын күрсәтә), «Яблоко» (Явлинский авторның борын төбенә үк китереп хуш исле алма иснәтә), КПРФ (тешлисе алма белән автор авызы арасына көрәк кадәрле сөялле кул – эшче-крестьян кулы килеп керә, ягъни товарищ Зюганов кулы), «Выбор» блогы, Россия хатын-кызлары партиясе һ.б.ш. Телевизор экраныннан Россия хатын-кызлары партиясенең сайлау алды бәхәсен карап утырганда, өенә үз хатыны җилләнеп-давылланып кайтып керә дә дөрләп кабынып китә:

*«– Син, тинтәк, туймас тамагыңны урыс хатыннары туйдырырлар, дип утырасыңмы әллә? Аларның үз тамаклары бар, нинди генәдер әле тамаклары! Күт кашып ятма, бар, әнә базарга чыгып, очсызрак чакта яшелчә-мазар алып кайт, аз булса да, запас әзерләп куйыйк»* (1, б. 83).

Бу алым белән автор укучының хисенә тәэсир итү көчен арттыра.

«Ташбакачылык» памфлеты исә үткен сәяси сатирага корылган. Ул Михаил Горбачёвны, Борис Ельцинны нык тәнкыйтьли – *саламторханлыкта, хөрәсәнлектә, борыла алмауда, койрыкта сөйрәлүдә, ягъни ташбакачылыкта* гаепли.

Памфлетта бик оста рәвештә сынландыру кулланылган:

*«Тиздән тәннәргә җылы йөгерәчәгенә мәмнүн булып, фил белән аю бик тәмләп гәп корып җибәргәннәр, урман хәлләрен энәсеннән җебенә кадәр тикшереп чыкканнар: урман хуҗасы постына күз салган яшь арысланның тетмәсен тетеп ташлаганнар, мышкылдык борыны да кибеп җитмәгән, кая*

*үрмәләмәкче була диген, нахал! Кичә генә бәбәй тапкан юлбарысның гайбәтен сатканнар: арысланнан микән, әллә ак барстан микән? Куркак яманаты чыккан куянга да өлеш чыккан: беркөн генә, бераз төшереп алып, төлкене куып йөргән, имеш...»* (1, б. 84)

«Ташбакачылык» памфлеты *сыныкка сылтау тапкан, коты ботка җитмәс, хет лопни, хет тресни, кояш күрде – ай алды, нахал, нәгъләт, әкренгәрәй, туйдан соң – дөмбергә калуы, йөрәгенә май булып ятты, сүз боткасы кайнату, боткасы пешмәде, майлы калҗа, эт – эткә, эт – койрыкка, астына су керә башлагач, шайтан таягы, ашыккан – ашка пешкән, иртәгесен ишәк кайгырткан, простой смертный, каһәр суккыры* кебек фразеологик гыйбарәләргә аеруча бай.

Шулай итеп, Флорид Әгъзамов 90 еллар татар матбугатында, аерым алганда, «Мәгърифәт» газетасында басылган фельетоннары һәм памфлетлары аша үзен сатира остасы итеп танытты.

**Әдәбият**

1. Флорид Әгъзамов: осталар остазы / төзүче В.З. Гарифуллин. Казан: Казан ун-ты, 2011. 155 б.

2. Гарифуллин В.З. Каләм көче (Татар журналистларының текст төзү осталыгы): Икенче китап. Казан: Казан ун-ты, 2011. 160 б.

## МЕДИАТЕКСТ В ТАТАРОЯЗЫЧНОМ РАДИО

**Р.А. Шигабутдинова,**
студент
Казанский (Приволжский) федеральный университет (Россия)
E-mail: shigab-regina09@yandex.ru
Научный руководитель: кандидат филологических наук, доцент **Л.Р.Сабирова**

**Аннотация.** Мы видим мир глазами сотрудников медиаиндустрии, и именно от них зависит то, как аудитория будет воспринимать и интерпретировать важнейшие события в стране и за рубежом. Всестороннее изучение медиатекстов важная и актуальная задача. В данной статье автор остановил свое внимание на специфике медиатекста в татароязычных радиостанциях.

**Ключевые слова:** медиатекст, радио, татарская журналистика.

**Summary :** We see the world with the eyes of the employees of the media industry, and it depends on them how the audience will perceive and interpret the major events in the country and abroad. Comprehensive study of media texts is an important and urgent task. In this article the author deals with the specifics of mediatext in the Tatar-speaking radio stations.

**Keywords:** media, radio, Tatar journalism.